ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур., 1

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
д.Куркачи, ул. Клубная,4

тел./факс 8(84365) 70-700 e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

---

КАРАР — ПОСТАНОВЛЕНИЕ

12 декабря 2019 ел — № 101

Иске-Казанавыл җирлеге башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен раслау турында”, 2019 елның 11 нояберендәге 99 номерлы Карарын гамәлдән чыгару турында

“Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында”, 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында”, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 1, 6 статьялары нигезләмәләре, “Ветеринария турында”, 1993 елның 14 маендагы 4979- I номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, санитар-эпидемиягә каршы чараларны норматив-хокукый җайга салу, шул исәптән сукбай этләрне тоту мәсьәләләре дә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән һәм җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәү сәбәпле, Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы Иске-Казанавыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен раслау турында”, 2019 елның 11 нояберендәге 99 номерлы Карары белән расланган Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап тоту Тәртибен гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар бастырып чыгарган (халыкка җиткереләгән) вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске-Казан авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Г.Р.Закирова